ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында” 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:
а) $6^1$ пунктта “рәсми” сүзен төшереп калдырырга;
б) 7 пунктта “рәсми сайтларда” сүзләрен “сайтларга” сүзләренә алмаштырырга;

2) $6^1$ статьяда “рәсми” сүзен төшереп калдырырга;

3) 9 статьяда:
а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы), дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар, күрсәтелгән мөлкәтне сату турында һәм аны сату нәтиҗәләре хакында мәгълүмати хәбәрләр, дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында еллык мәгълүмат торглар үткәрелү турында мәгълүмат урнаштыру өчен “Интернет” челтәрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән рәсми сайтка (алга таба – “Интернет” челтәрендә рәсми сайт) урнаштырылырга тиеш. Әлеге пунктта күрсәтелгән дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турындагы мәгълүмат өстәмә рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән “Интернет” челтәрендәге сайтка урнаштырыла.”;
б) 2 өлештә “сайтларда” сүзен “рәсми сайтка, сайтка” сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә “Интернет челтәрендәге сайтларда” сүзләрен “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтка” сүзләренә алмаштырырга;

г) $3^1$ өлештә “сайтларда” сүзен “рәсми сайтка” сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 өлештә “Интернет челтәрендәге сайтларда” сүзләрен “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтка” сүзләренә алмаштырырга;

4) 16 статьяның 4 пунктында “сайтларда” сүзен “рәсми сайтка” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2016 елның 3 октябре
№ 76-ТРЗ